КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 апрель г.Казань № 241

2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасын Бюджет кодексы, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый стратегиясен раслау турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән 2019 – 2021 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразын эшләү графигын расларга (алга таба – График, Фараз).

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына үз юнәлешләре буенча фараз күрсәткечләрен График нигезендә «Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үсеше» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасына (алга таба – Система) тапшыруны һәм кертүне тәэмин итәргә.

3. Тәкъдим итәргә:

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы предприятие һәм оешмаларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары соравы буенча билгеләнгән тәртиптә Фараз эшләү өчен кирәкле мәгълүматны җибәрергә;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына Графикта билгеләнгән вакытларда фараз күрсәткечләрен Системага кертүне гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасында үз эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы предприятие һәм оешмаларга җитештерү-финанс эшчәнлекләренең фараз күрсәткечләрен Системага кертүне гамәлгә ашырырга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына соратулар җибәргәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма

органнарына мәгълүмат биргәндә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгълүматны саклау режимы тәэминителергә тиеш.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин